# ТАНЫШ ТҮГЕЛ ИЛЛӘР, САХРА-ЧҮЛЛӘР, ДӘРЬЯЛАР АША...

Туган яктан ерак китеп,
Диңгезләр кичтем...
*Г. Зәйнашева*

Соңгы елларда язма мираска мөрәҗәгать итү, аны җентекле өйрәнү эше активлашып китте. Чөнки халыкның олы тарихы, рухи тормышы аның язма әсәрләрендә теркәлеп калган. Әйтергә кирәк, татар тарихы һәм милли тематика белән кызыксыну арта бара. Бу күренеш, әлбәттә, халкыбызның үзаңы үсешенә дә нык бәйле.

Татар халкының әдәби мирасында географик мәгълүматлар тупланган, эчтәлеге ягыннан көндәлекне дә хәтерләткән, төрле чорларга караган үзенчәлекле жанрдагы әсәрләре бар. Алар, нигездә, юл йөрүләр белән бәйле сәфәр язмалары. Мондый әсәрләрне юлъязмалар яки сәяхәтнамәләр дип атап йөртәләр. Бу жанр кайбер башка әдәбиятларда да киң таралган һәм бик популяр. Чөнки сәяхәтнамәләр укучының дөньяга карашын киңәйтә, фикерен ача, калебен куандыра.

Сәяхәтнамәләрне халык электән үк яратып укыган һәм әлеге жанрның популярлыгы хакында аерым фикерләр дә матбугатта инде күптән әйтелгән: «Тәрәккый иткән кавемнәрнең укыдыгы әдәбиятлары арасында иң кызыклы вә рәгъбәтле (күтеп алынган), инсанның фикерене ачуда, дөньяда яшәмәктә улан башка кавемнәр илә таныштыруда сәяхәтнамәләрдән артык нәрсә юктыр; шул сәбәптән тәрәккый иткән кавемнәр ел саен төрле гаҗәибне туплаган сәяхәтнамәләр нәшер итеп, укучыларның калебләрене шатландырып, фикерләрене арттырып тормактадыр»[1].

Димәк, сәяхәтнамәләр, халыкның иҗтимагый аңы, үз-үзен танып белүе билгеле бер баскычка күтәрелгәндә, милли үзаң формалашуын күрсәтә торган махсус әдәби-гыйльми жанрлар рәтендә тора. Фәнни әдәбиятта бу жанрга карата төрле билгеләмәләр, аңлатмалар очрый, әмма алар барысы да бу жанрның юл йөрүләр, сәфәр белән бәйле икәнен искәртәләр, иң беренче чиратта шуңа басым ясыйлар.

Әдәбият белеме сүзлеге билгеләвенчә: «Сәяхәтнамә — сәфәр кылучы, сәяхәт итүче кешенең укучыга таныш булмаган җирләр, илләр, халыклар турында белешмәләр бирүе, язмалар, көндәлек, очерк, мемуар формасында төрле вакыйгахәлләрне хикәяләве»[2]. Татар энциклопедиясендә дә аның әдәби жанр булуына басым ясала: «Сәяхәтнамә (сәяхәт турында китап) — әдәби жанр. Сәяхәттә

[1] *Гыйсмәти Г.* Мәвараэннаһердә сәяхәт // Әхбар. — 1908. — 29 февраль.
[2] Әдәбият белеме : терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. — Казан : Мәгариф, 2007. — 169 б.

күргәннәрне тасвирлаган көндәлекләр, әдәби язмалар һәм сәяхәткә бәйле мемуар характердагы әсәрләр. Күбрәк проза белән, сирәгрәк очракларда шигъри формада иҗат ителә»[1]. Төрле чыганакларда сәяхәтнамәгә бирелгән билгеләмәләргә игътибар итсәк, жанрга хас уртак сыйфатны күрәбез: ул — сәфәр, сәяхәт нәтиҗәсендә язылган әсәр.

Сәяхәт мотивларына мөрәҗәгать итү — халык иҗатына да хас алым. Теге яки бу күләмдә сәфәр элементлары, сәяхәт коллизияләрен файдалану, сәяхәтнамәләр стилен куллану анда күптәннән чагылыш табып килгән. Мәсәлән, «Мең дә бер кичә»дәге сюжетларның күбесе сәфәр, юл йөрүләр белән бәйле. Яңа илләр күрү, башкача яшәү рәвеше белән танышу, дөньяда булмаганча, фантазиягә корылган тасвирлаулар: океан уртасында кыргый кешеләр яшәгән утрауларга барып чыгу, җиде кат җир астындагы мәгарәләргә керү, анда төрле асылташлар белән бизәлгән бай җиһазлы бүлмәләр, төрле тормыш, яшәү атрибутларының булуы һәм төрле юллар белән кешеләрнең шунда барып эләгүе һ. б. Мондый хәлләрне, беренчедән, кешенең үз теләгеннән тыш, аңа бәйле булмаган тормыш ситуациясе китереп чыгарса, икенчесе, кеше, алда төрле маҗаралар көтәсен, юлның бик җиңел генә булмавын белә торып, аңлы рәвештә, бер-бер максатына ирешер өчен, шундый хәвефле дә, хәтәр дә юлга чыгып китә. Шулай ук герой һәрбер зирәк акыллы адәм баласына хас кызыксыну, чит-ят илләр белән танышасы килү, дөнья күреп, сәүдә итеп йөрү теләге белән дә маҗаралы сәфәргә юнәлә. Шундыйлардан «Синдбад сәяхәте», эчтәлегенә кәләш эзләп сәфәр чыгу салынган «Таҗелмөлек һәм Бәдигыльҗамал» кыйссасы, «Мәҗмугыл хикәят»тә дә сәяхәтләр коллизиясе шактый гына урын алган. Әлбәттә, мондый юнәлештәге әсәрләрне шактый санап үтәргә мөмкин. XVIII гасырда Англиядә дә сәяхәтнамә рәвешендә язылган мәгърифәтчелек романнары иҗат ителә (Д. Дефо. «Робинзон Крузо» (1719), Дж. Свифт. «Гулливер сәяхәтләре» (1706)), Россиядә А. Н. Радищевның «Петербургтан Мәскәүгә сәяхәт» (1790) әсәре шундыйлардан санала ала.

Фантастик сюжетлы сәяхәт мотивыннан файдаланып язылган әсәрләр яки сюжеты белән композициясе документаль сәяхәтнамәләргә охшатып иҗат ителгән һәм сәяхәтнамәләр, юльязмалар жанрын баетып, аның бер төрен тәшкил иткән әсәрләр меңьеллык тарихы булган татар әдәбиятында да аз түгел.

Документаль сәяхәтнамәләр еш кына реаль-фактик мәгълүматлар, әдәби сурәтләүләр белән бик тыгыз үрелә. Шуңа күрә мондый әсәрләрнең танып белү (тарихи-географик һ. б.) ягыннан да әһәмияте бар.

Юльязмалар жанрын билгели торган төп критерий булып әсәрнең түбәндәге төзелеше тора: автор билгеле бер максат белән, яшәгән җирен, өен, гаиләсен калдырып, юлга чыга (хаҗга юл тота, дипломатик миссия үтәп, сәүдә максаты белән чит илгә бара, журналист буларак командировкага юнәлә, турист булып дөнья күреп йөри һ. б.). Юлда күргән хәлләрне сурәтли. Тиешле урынга барып җиткәч, күргәннәрен, кичерешләрен тасвирлый, теге яки бу вакыйга-хәлләр турында хөкем йөртә һәм, алдан билгеләнгән максат, гамәлләрне үтәп, туган җиренә әйләнеп кайта. Менә шушы конкрет, ябык (билгеле бер) вакыт арасындагы сәяхәтче бәян иткән күренеш-вакыйгалар сәяхәтнамәләрнең, юльязма

[1] Татар энциклопедия сүзлеге. — Казан : ТР ФА Татар энциклопедиясе институты, 2002. — 557 б.

әдәбиятның нигезендә ята, һәм ул төп билгеләү критерие булып тора. Моннан чыгып фикер йөрткәндә, сәяхәтнамә функциональ жанрлар рәтендә тора, дияргә тулы нигез бар. Аның төп функциясе — сәфәрченең санап үтелгән максатларны алга куеп юл йөрү нәтиҗәсендә күргәннәре, кичергәннәре турында үзенең заманы белән авазлаш яки оригиналь уй-фикерләрен башкаларга җиткерү.

Жанрның үсешенә төрле факторлар тәэсир итә, әмма аның яшәве өчен кирәк булган шарт булып сәфәр үзе һәм чынбарлыктагы реаль, конкрет кешеләрнең юлы, бер урыннан икенче урынга күчүе — сәяхәте тора.

Әдәбиятта жанрларның күп төре билгеле. «Һәр жанрның үз әдәби объекты һәм һәрберсенең чынбарлыкны күзаллауда үз офыклары бар»[1]. Һәр жанрның билгеле бер системага нигезләнеп оешканлыгын исәпкә алсак, автор язу процессында үзе сайлаган жанр таләпләренә, шул жанрның әдәби системасына буйсынып иҗат итә, чөнки тормыш материалына карата һәр жанрның үзенең эчке таләбе бар. Жанр формасы һәрвакыт эчтәлек белән бәйле икәнлекне дә истән чыгармаска кирәк. Жанрлар системасында гомумән һәм аерым алганда һәр жанрга динамизм хас, сәяхәтнамәләр өчен бигрәк тә, әйтергә кирәк, ул төп сыйфат. Чөнки сәяхәтнамә беренче чиратта сәфәргә — дөнья күрү, илләр гизүгә корылган.

* * *

Сәяхәтнамә жанрының барлыкка килүе борынгы чорларга барып тоташа, дидек. Сәяхәт нәтиҗәсе буларак иҗат ителгән әсәрләр күп халыкларда борыннан ук язылып килгән. Шактый гына үрнәкләре дә сакланып калган. Хәтта безнең эрага кадәр үк язылганнарын да күрсәтергә мөмкин.

Сәяхәт язмалары — антик дәвердә, урта гасырларда, Яңарыш чорында язылганнары да — бер яктан, фәнни танып белү, икенчедән, әдәби әсәр, сәнгатьле сүз үрнәге буларак та үз кыйммәтләрен югалтмаганнар. Сәяхәтнамәләр язу традициясе бүгенге көндә дә дәвам итә. Татар әдәбиятында аның матур үрнәкләрен күпләп китерергә мөмкин (бигрәк тә XIX гасырдан башлап).

Борынгы юнан, кытай, гарәп һәм фарсы, соңрак чорларда Көнбатыш һәм русларның әдәби мираслары мисалында да сәяхәтнамә жанрында язылган әсәрләрне күрергә мөмкин. Шундыйлардан, мәсәлән, Юлий Цезарьның «Галлия сугышы хакында язмалары» (б. э. к. I гасыр), борынгы грек сәяхәтчесе, тарихчыгалим Геродотның (б. э. к. 484—425 еллар) тарихи-географик язмалары. Үзенең атаклы «Тарих»ын язар өчен, заманында билгеле булган җирләрне ул үзе йөреп чыга. Борынгы грек географы һәм тарихчысы, бөтен гомерен сәяхәттә үткәргән Страбонның әтрафлы һәм тәфсилле башкарылган унҗиде томлык монументаль «География»се (I гасыр), урта гасырларда яшәгән сәүдәгәрләр һәм сәяхәтчеләр, илгизәрләрнең язмалары бик күп сакланып калган. Ерак экзотик илләрдә булган сәяхләрнең юлъязмалары дөнья прозасы шедеврларына әйләнделәр, дияргә мөмкин. Мәсәлән, Плано Карпини, Гильом де Рубрук, Марко Полоның киң итеп язылган сәфәр язмалары, отчёт-хисаплары шул заманнар турында әтрафлы мәгълүматларга искиткеч бай булулары белән аерылып торалар.

---

[1] *Мартьянова С., Хализев В.* Поэтика лирических жанров и пушкинистика // Вопросы литературы. — 1987. — № 4. — С. 237.

XII гасырда европалылар Үзәк Азиянең эчке районнарына үтеп керә башлыйлар. Башта дипломатия һәм миссионерлык максатлары белән монахлар юл ачалар. Соңрак ул ерак җирләргә сәяхәтчеләр дә барып җитәләр.

Италия монахы, сәяхәтче Джованни Плано Карпини (1182—1252), Рим папасы Иннокентий IV фәрманы буенча, 1245 елда монгол ханнары белән дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштыру максатыннан Монголиягә — Каракомга бара. Алтын Урда ханы Батый урдасында — Сарай-Бату шәһәрендә була. Аның «Монголлар тарихы» исемле сәяхәт язмалары беренчеләрдән булып Европаны Көнчыгыш дөньясы белән таныштыра. Сәяхәтләре нәтиҗәсе итеп ул күп халыкларның этнографиясенә бәйләнешле хезмәт язып калдырган. Анда болгар-татарлар турында да мәгълүматлар бар[1].

Француз короле Людвиг IX тарафыннан монах Гильом де Рубрук та (1230—1291), дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштыру өчен, 1253—1255 елларда Монголиягә җибәрелә. Миссия башлыгы булып барган бу сәяхнең үз сәфәре турында «Көнчыгыш илләренә сәяхәт» исемле үтә кызыклы һәм мәгълүматка бай юлъязмалары билгеле. Ул күп илләрдә, шул исәптән Кырым һәм Идел буе шәһәрләрендә дә булган. Аларда җирле халыкның тормышына кагылышлы, болгарлар, кыпчаклар (татарлар) турында да хәбәрләр күп очрый[2].

Италия сәяхәтчесе Марко Полоның (1254—1324) егерме дүрт елга сузылган (1271—1295) Кытайга сәяхәте һәм анда күргәннәре турында «Китап» (1298) исемле язмалары Европа халыклары арасында шулай ук киң таралыш таба[3].

XV—XVII гасырлардагы Бөек географик ачышлар чорында да бик күп юлъязмалар, сәфәр язмалары барлыкка килгән. 1466 елда Тверь сәүдәгәре Афанасий Никитин үзенең Һиндстанга сәфәре һәм бу «серле» ил халыклары тормышының төрле якларын чагылдырган «Өч диңгез артына сәяхәт» дигән юлъязмалары белән ватандашларын таныштыра. Географик ачышлар ясаган илгизәр сәяхәтчеләр: Христофор Колумбның борт журналы, Америго Веспуччиның хатлары, Фернан Магелланның юлдашы А. Пигафеттиның көндәлек дәфтәре, Адам Олеарийның «Московиягә сәяхәтне тасвирлау...» (XVII гасыр), 1517 елда Германиядән Мәскәүгә илче булып килгән сәяхәтче, тарихчы Сигизмунд Герберштейн (1486—1566) язмалары сакланган. С. Герберштейн исә Казан татарлары тормышы белән дә якыннан кызыксынган, аларның көнкүрешенә, этнографиясенә караган мәгълүматлар китергән[4].

XV гасырда Венеция сәүдәгәре Йосафат Барбаро һәм Венециянең 1474—1477 елларда Персиядәге илчесе Амброджо Кантарининың Кырымга, Россия һәм Персиягә сәяхәтләре вакытында Идел буйларында яшәгән халыклар, Казан, Мәскәү шәһәрләре турында язмалары бар[5].

Әлеге сәяхәт язмалары үз чиратында әдәбиятта сәяхәтнамә, юлъязма алымнарын куллануның үсешен күрсәтә торган фактлар булып санала алалар.

---

[1] *Карпини Джованни Плано.* История монголов // Гильом де Рубрук. Путешествие в Восточные страны / ред., вступ. сл. и прим. Н. П. Шастиной. — М. : Географгиз, 1957. — С. 23—83.

[2] *Рубрук Гильом де.* Путешествие в Восточные страны // Карпини Джованни Плано. История монголов. — М. : Географгиз, 1957. — С. 87—194.

[3] Книга Марко Поло / пер. И. П. Минаева, ред. и вступ. ст. И. П. Магидовича. — М. : Географгиз, 1956. — 376 с.

[4] *Герберштейн Сигизмунд Барон.* Записки о Московии. — СПб., 1866. — 228 с.

[5] Барбаро и Кантарини о России. — Л. : Наука, 1971. — 275 с.

Көнбатыш сәяхләре язмаларының кайберләрендә татарларга мөнәсәбәте булган мәгълүматларны да очратырга мөмкин. Мәсәлән, инглиз дипломаты, сәяхәтче һәм сәүдәгәр Антони Дженкинсон (1526—1610), яңа сәүдә базарлары эзләп, Европа, Азия һәм Африка илләренә сәяхәт итә. Англиянең илчесе сыйфатында ул дүрт мәртәбә Мәскәү дәүләтендә була. 1558—1559, 1562—1564 елларда рус патшасы Явыз Иван рөхсәте белән Россия аша Иранга һәм Урта Азиягә сәфәр кыла. Бу сәяхәте турында «Лондоннан Мәскәүгә сәяхәт» дигән ике томлык юлъязмалары 1866 елда Лондонда һәм соңрак, кыскартылып, рус теленә дә тәрҗемә ителеп басыла[1]. Идел буйлап түбәнгә — Каспийга төшкәндә, Дженкинсон һәм иптәшләре Казанда, Әстерханда, Бакуда, Мангышлак ярымутравында тукталалар. Бу вакытта инде Идел буе халыклары — Казан ханлыгы, Әстерхан ханлыгы яулап алынган. Шушы тарихи вакыйгадан соң Идел буенда хөкем сөргән фаҗигале хәлләр А. Дженкинсонга көчле тәэсир итә. Болар аның юлъязмаларында да чагыла. Аның сәяхәтнамәсендә Казан ханлыгы җимерелү белән барлыкка килгән вазгыятьне күз алдына китерергә мөмкинлек бирә торган мөһим мәгълүматлар бар.

Юлъязма әсәрләр борынгы һәм урта гасыр Көнчыгыш илләрендә дә булган. Мәсәлән, борынгы Кытай сәяхәтчесе Чжан Цянь язмалары. Ул II гасырда Кытайдан Урта Азиягә сәяхәт итә. Чжан Цянь Бөек ефәк юлын ачучы буларак та тарихка кереп калган. Шулай ук будда монахы һәм сәяхәтчесе Фа Сянь 399—414 елларда Һиндстан һәм Азиянең зур өлешен йөреп чыга. Нәтиҗәдә Кытай белән Һиндстан арасында мәдәни бәйләнешләрнең башлангычына нигез сала. Үзенең унбиш елга сузылган сәфәре турында «Фугонзи» («Описание буддийских государств») исемендәге юлъязмаларында язып калдырган. Үзе йөргән җирләрдәге утыз дәүләттә була һәм алар турында беренчеләрдән булып саллы тарихи-географик мәгълүматлар бирә. Шулай ук Сөләйман Басрый язмалары (IX гасыр), Васко де Гаманың лоцманы ибн Мәҗид язмалары (XVI гасыр), төрек сәяхе Әүлия Чәләбинең (1611—1683) ун томлык юлъязмаларын (XVII гасыр) һ. б. санап китәргә мөмкин.

Гарәп сәяхәтчеләре дә бик борынгыдан ерак илләргә сәфәр кылалар, һәм аларның китаплары, юлъязмалары безнең көнгәчә килеп җиткәннәр. Шундыйлардан Әхмәд ибне Фадланның (X гасыр) Бохара, Харәзм аша Идел буе Болгарстанына килүе турында язылган, «Рисалә» дип исемләнгән сәяхәтнамәсе безнең өчен бик әһәмиятле. Утыз елдан артык сәяхәттә йөргән, шулай ук Болгарда булган Әбү Хәмид әл-Гарнатыйның (1080—1169) «Муэриб ән-бәян гаҗәиб әл-Мәгъриб» («Көнбатыштагы кайбер гаҗәиб хәлләрне ачык бәян итү») һәм «Төхфәтел-әлбаб вә нухбәтел-гаҗәб» («Галимнәргә бүләк һәм гаҗәиб әхвәлләрдән сайлап алынган өзекләр») дип исемләнгән тарихи яктан әһәмиятле сәяхәтнамәләре сакланып калган.

XIV гасырда тагын бер тынгысыз гарәп сәяхәтчесе Ибне Баттута Әбү Абдаллаһ Мөхәммәд (1304—1377) гомеренең күп өлешен илләр гизеп үткәрә. Мисыр, Согуд Гарәбстаны, Месопотамия, Сурия, Кече Азия, Иран, Кырым, Алтын Урда, Урта Азия, Һиндстан, Кытай, Испания, Судан, Африка илләрендә була. Маршрутының озынлыгы буенча ул урта гасыр сәяхәтчеләре арасында берен-

[1] *Дженкинсон А.* Путешествие из Лондона в Москву. 1557—1558 // Английские путешественники в Московском государстве в XVI веке. — Л., 1937. — С. 187—226.